Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә топ гомуми белем мәктәбе

“Расланды”
Педагогик киңәшмә
Беркетмә №1, 26.08.2021.
Боерык №109. 27.08.2021
Мәктәп директоры:
________ /Мингатина Г.Г./

8 нче сыйныф өчен әдәбияттан
**эш программасы**
*(атнага 2 сәг.,барлыгы 70 сәг.)*

Төзүче: Нугуманова Рәмзия Мингата кызы,
беренче категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

“Килешенде”
Директор урынбасары: ________ /Вилданова Ф.И./ “26 ” август 2021.

“Каралды”
МБ утырышы,беркетма №1, “24”август 2021.
МБ житәкчесе: ________/Нугуманова Р.М./

**8 нче класста татар әдәбиятын өйрәнү буенча көтелгән нәтиҗәләр.**

| Бүлек исеме | Предмет нәтиҗәләре | | Метапредмет нәтиҗәләре | Шәхси нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнә | Укучы өйрәнергә мөмкинчелек ала | | |
| **Сәнгать төре буларак әдәбият** | нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу; узган сыйныфларда өйрәнгән әсәрләр мисалында XX гасыр башы татар әдәбиятының сүз сәнгате буларак үзенчәлекләрен билгели алу. | милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү; өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү; геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу; төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре.<br>2. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен модельләрне үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе.<br>3. Аңлап уку.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, рефлексия ясый.<br>2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү.<br>3. Нәтиҗәгә ирешү процессында үз эшчәнлегеңә контроль ясый белү.<br>4. Үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлектә катнаша, яшьтәшләре белән төркемгә | Укучының башкаларны кабул итүе, аңлавы, фикерләрен җиткерә алуы, үз уңышларының (уңышсызлыкларыңның) сәбәпләре турында фикер йөртү. Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.Үз милләтеңә,үз телеңә хөрмәт тәрбияләү. Татар теленең татар халкы өчен төп милли –мәдәни кыйммәт булуын,ана телендә шәхеснең әхлакый һәм рухи яктан формалашуындагы ролен аңлау.Әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | берләшә, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. | |
| **Урта гасырлар әдәбияты. Казан ханлыгы чоры** | «Нәсыйхәт» шигырендәге дини-суфичыл фикерләрне билгели алу, автор позициясен ачыклау һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу; әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм | төрле чыганаклар белән эшли белү: аларны таба, мөстәкыйль рәвештә куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һәм бәяли алу;сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре.<br>2. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, модельләрне үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, рефлексия ясый. 2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү. | Үзеңдә горурлык һәм гражданлык хисләре булдыру.Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.<br>Укуга җаваплы караш, хезмәткә хөрмәтле караш формалаштыру, социаль кирәкле хезмәттә катнашу.<br>Кеше тормышында һәм җәмгыятьтә гаиләнең кирәклелеген аңлау.<br>Гомумкешелек нормаларын белү, җәмгыятьтә үзеңне тоту |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | әһәмиятен аңлап бәяли белү; | | **Коммуникатив күнекмә.** 1. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлектә катнашу, яшьтәшләре белән төркемгә берләшу, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. | кагыйдәләрен һәм формаларын үзләштерү. |
| **XIX гасыр әдәбияты. Мәгъриф әтчелек әдәбияты** | укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеру; автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу; мәгърифәтчелек әдәбияты үрнәге буларак, стиль үзенчәлекләрен күрсәтә белү; | өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү; геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу; төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре<br>2. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, модельләрне үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе.<br>3. Аңлап уку.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, рефлексия ясый. 2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү.<br>3. Нәтиҗәгә ирешү процессында үз эшчәнлегеңә контроль ясый белү.<br>4. Үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлектә катнаша, яшьтәшләре белән төркемгә берләшә, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. | Үз милләтеңне, Ватаныңны ярату.Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.Җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү; күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү. Үзеңне милләтеңнең вәкиле итеп тану; туган телеңне , туган төбәгеңнең, милләтеңнең тарихын һәи мәдәни мирасын белү. Кеше тормышында һәм җәмгыятьтә гаиләнең кирәклелеген аңлау, гаилә әгъзаларына хөрмәт белән караш һәм кайгыртучан мөнәсәбәт. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **XX гасыр башы әдәбиятының үзенчәлеге.** | сөйләм осталыгына ирешү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикереңне дәлилли, кирәк икән - үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә^аңлата алу; «импрессионизм алымы», «сызлану фәлсәфәсе» төшенчәләрен үзләштерү; | төрле чыганаклар белән эшли белү: аларны таба, мөстәкыйль рәвештә куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һәм бәяли алу; сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре.<br>2. Аңлап уку.<br>3. Сүзлекләрне актив куллана белү сәләтен үстерү.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, рефлексия ясый. 2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру; язма һәм телдән сөйләм төрләрен оста файдалана белү. 3. Информацион-коммуникатив технологияләр өлкәсендә компетентлыкны формалаштыру һәм үстерү. | Үзаң үсешенә ирешү, милләтне, Ватанны ярату.Укучының башкаларны кабул итүе, аңлавы, фикерләрен җиткерә алуы.<br>Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.<br>Эшчәнлек стилен формалаштыру.<br>Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү: милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру; |
| **XX гасыр башы әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр** | Мөхәммәдьяр һәм М. Гафуриның Нәсыйхәт әсәрләрен чагыштыру аша, әдәбиятта традиция һәм яңалык турында нәтиҗә ясауга ирешү; Мөхәммәдьяр һәм М. Гафуриның Нәсыйхәт әсәрләрен һәм Г. Тукайның дини темага язылган шигырьләрен | нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү. | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре.<br>2. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модельләрне үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, | Үзаңны үстерү, милләтне, Ватанны ярату, үзеңдә горурлык һәм гражданлык хисләре булдыру.Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү.Әйләнә-тирәдәге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | чагыштыру аша, әдәбиятта традиционлык турында нәтиҗә ясый белү; | | рефлексия ясый. 2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү. **Коммуникатив күнекмә.** 1. Үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру; язма һәм телдән, монологик һәм контекст сөйләм төрләрен оста файдалана белү. 3. Информацион-коммуникатив технологияләр өлкәсендә компетентлыкны формалаштыру һәм үстерү. | чынбарлык, социаль шәхес кыйммәтләренә, бердәм башкарыла торган эшчәнлеккә уңай караш тудыру. Башка шәхеснең кыйммәтләренә хөрмәт. |
| **XX гасыр башы әдәбиятында психологизм** | материалны төркемли, үз фикереңне дәлилли, нәтиҗәләр чыгара, өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү; геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу; материалны гомумиләштерә белү, әдәби алымнарны табып, шулар нигезендә фәлсәфи фикерне ачыклау күнекмәсенә ия булу; язу һәм сөйләм осталыгына ирешү, | әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү; төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу; әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе. 3. Аңлап уку. **Регулятив күнекмә.** 1. Теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, рефлексия ясый. 2.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү. 3. Нәтиҗәгә ирешү процессында үз эшчәнлегеңә контроль ясый белү, тәкъдим ителгән шартлар һәм таләпләр рамкасында чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымыңның ысулларын билгеләү, үзгәреп торучы ситуацияләрдә үз гамәлләреңә төзәтмәләр кертә белү. | Үзеңдә җаваплылык хисе булдыру.Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау, үзбәягә сәләтле булу. Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү: миллигорурлык, гражданлыкхисләреформалаштыру; әхлакнормаларын, җәмгыятьтәяшәүкагыйдәләренү зләштерү. Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 5. Сүзлекләрне актив куллана белү сәләтен үстерү.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлектә катнаша, яшьтәшләре белән төркемгә берләшә, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. | |
| **XX гасыр башы әдәбиятында сызлану фәлсәфәсе** | хикәянең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу; әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта тел-сурәтләү алымнарының, әһәмиятен аңлап бәяли белү; | өйрәнелгән әсәрләрне мөстәкыйль шәрехли белүгә ирешү; әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү; үз фикереңне дәлилли, кирәксә- үзгәртә-төгәлли, нәтиҗәләр чыгара белү, | **Регулятив күнекмә.** 1.Максатка ирешү юлларын укытучы ярдәмендә планлаштыра белү.<br>2. Уку мәсьәләләренең дөреслегенә, аны чишкәндәге үз мөмкинлекләреңә бәя бирә белү.<br>**Танып-белү күнекмәсе.** 1. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре. 2. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлекне оештыра, яшьтәшләре белән төркемгә берләшә, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. 2. Үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру; язма һәм телдән, монологик һәм контекст сөйләм төрләрен оста файдалана белү. | Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәттә булу.Үзеңдә җаваплылык хисе булдыру.Шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру; аралашу компетенциясе – барлык сөйләм эшчәнлеге төрләренә ия булу, урта сыйныф укучыларына хас булган кызыксыну даирәсенә, психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә туган телдә аралаша белү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **XX гасыр башы әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе** | әдәби әсәрне аңлап уку, мөстәкыйль үзләштерү күнекмәләренә ия булу; трагедиянең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, әсәрнең кайсы төр һәм жанрга каравын аера белү;<br>өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү; материалны төркемли, гомумиләштерә белү, | мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу; үз карашларыңны раслый һәм дәлилли, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итә белү;милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итү; | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Экологик фикерләүне формалаштыру һәм үстерү, аны танып-белү, коммуникатив, социаль практикада һәм профессиональ ориентациядә куллана белү. 2. Хәбәрлек сүзләрне тану; төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. 3 . Төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Уку мәсьәләләренең дөреслегенә, аны чишкәндәге үз мөмкинлекләреңә бәя бирә белү.<br>**Коммуникатив күнекмә. 1.** Укылган текстлар буенча сораулар бирә алу. 2. Бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, фикер әйтү, автор фикере белән чагыштыру; бердәм эшчәнлектә мөмкин булган рольләрне билгели белү. | Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәттә булу.Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә, гражданлык позициясенә (карашына) карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү.Үзеңдә җаваплылык хисе булдыру. Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:<br>милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;<br>әхлак нормаларын үзләштерү. |
| **20-30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе һәм яңа** | укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, аның кайсы төр һәм жанрга каравын аеру; автор позициясен | сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү; әхлак | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү. 2. Электрон эзләү системалары белән узара бәйләнеш булдыру.<br>**Регулятив күнекмә.** 1. Үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында | Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәттә булу.Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә, гражданлык позициясенә (карашына) карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **тормыш өчен көрәш романтикасы** | ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу; әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының үзенчәлекләрен, әһәмиятен аңлап бәяли белү; | нормаларын үзләштерү, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үтәү. | үзбәя, карар кабул итә белү.2. Нәтиҗәгә ирешү процессында үз эшчәнлегеңә контроль ясый белү, тәкъдим ителгән шартлар һәм таләпләр рамкасында чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымыңның ысулларын билгеләү, үзгәреп торучы ситуацияләрдә үз гамәлләреңә төзәтмәләр кертә белү. 3. Сүзлекләрне актив куллана белү сәләтен үстерү. **Коммуникатив күнекмә.** 1. Аралашу бурычларын билгели белү һәм аңа туры килгән сөйләм чараларын сайлап ала белү. 2. Үз фикереңне аргументлар китереп, әдәпле яклый белү. 3. Үз хаталарыңны лаеклы рәвештә таный белү һәм аны төзәтә белү. | Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү. |
| **Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты** | шигырьләрне тиешле интонация, пафос белән, логик басымнарны шигырьдәге мәгънәләргә туры килерлек итеп куеп, тиешле урында паузалар ясап укуга ирешү; образларны күрсәтеп, алар арасындагы бәйләнешләрне аңлата | Бөек Ватан сугышының максатларын, характерын һәм анда катнашкан халыкларның сугышка мөнәсәбәтен истә тотып, Бөек Җиңүнең кыйммәтен бәяли алу; Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән әдәбиятның үзенчәлекләрен күрсәтә белү | **Танып-белү күнекмәсе. 1.** Укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве; мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү. **Регулятив күнекмә.** 1. Мөстәкыйль рәвештә уңышының яки уңышсызлыгының сәбәпләрен ачыклый белү. 2. Уңышсызлык ситуацияләреннән чыгу юлларын | Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү: милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру.Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәттә булу.Үзаңны үстерү, милләтне, Ватанны ярату, үзеңдә горурлык һәм гражданлык хисләре булдыру.Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | алу; фикер һәм хис тәңгәллеген, сурәтләү чараларын анализлый белү. | | таба белү. 3. Чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымнарның кайсылары уку мәсьәләләрен чишкәндә уңай продукт алуга китерүен үткәнгә карап (ретроспективно) билгеләү.<br>**Коммуникатив күнекмә.** 1. Диалог барышында үз фикереңне дәлилләп бирә, партнер фикерен сорый белү. 2.Аралашу бурычларын билгели белү һәм аңа туры килгән сөйләм чараларын сайлап ала белү. 3. Үз фикереңне аргументлар китереп, әдәпле яклый белү. | |
| **60-80 нче еллар әдәбияты** | әсәрнең язылу вакытына игътибар итеп, сугыш чоры тудырган авырлык, фаҗигаләр һәм аларның сәбәпләре турында аңлата белү; әсәрнең исеменә салынган күчерелмә мәгънәне вакыйгалар белән бәйлитабигать белән тәңгәл килгән матурлыкны - әсәрнең поэтикасын, сәнгатьлелек чараларын анализлый белү. | өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү; геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу; төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу | **Танып-белү күнекмәсе.** 1. Аңлап уку.Үз эшчәнлеге максатларына туры килгән,соралган информацияне текстан табу. 2. Текст эчтәлегендә ориентлашу,текстның тулы мәгънәсен аңлау. 3. Тема тирәсендәге төп белгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. 4. Төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү.<br>**Регулятив күнекмә. 1. К**өтелгән нәтиҗәгә ирешә яки ирешә алмау сәбәпләрен аргументлаштырып, үз эшчәнлегеңә бәя бирү.<br>**Коммуникатив күнекмә. 1. И**нформацион һәм коммуникатив | Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү: милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәттә булу.Үзаңны үстерү, милләтне, Ватанны ярату, үзеңдә горурлык һәм гражданлык хисләре булдыру.Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | уку мәсьәләләрен чишү өчен компьютер технологияләрен куллана белү.2.Аралашу бурычларын билгели белү һәм аңа туры килгән сөйләм чараларын сайлап ала белү. 3. Үз фикереңне аргументлар китереп, әдәпле яклый белү. | |

**8 нче сыйныфта татар әдәбиятының эчтәлеге.**

| Бүлекнең исеме | Кыскача эчтәлек | Сәг. |
|---|---|---|
| **Сәнгать төре буларак әдәбият** | Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. | **1 с.** |
| **Урта гасырлар әдәбияты. Казан ханлыгы чоры** | Казан ханлыгы чорына кыскача тарихи, мәдәни, әдәби күзәтү. Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында мәгълүмат. «Нәсыйхәт» шигыре. Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б. Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек. Символик образлар. | **2с.** |
| **XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек әдәбияты** | Чорга кыскача тарихи күзәтү. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Муса Акъегетзаданең «Хисаметдин менла» повесте. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Әдәбиятта яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Повесть жанры. Әсәрнең сюжеты, тема, проблема, идеясе. Мәгърифәтчелек әдәбиятында төп тема - аң-белем, әхлак, тәрбия, һөнәрле булу, төп каршылык – искелек һәм яңалык көрәше. Мәгърифәтле шәхеснең сурәтләнеше: укымышлы, һөнәрле булу, дини кануннарны, Коръәнне яхшы белү. Хатын-кыз азатлыгының алгы планга куелуы. | **3с.** |
| **XX гасыр башы әдәбиятының үзенчәлеге.** | Чорга кыскача тарихи күзәтү. XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. | **1с.** |

| | | |
|---|---|---|
| **XX гасыр башы әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр** | М.Гафуриның «Нәсыйхәт» шигыре. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Әдәбиятта үгет-нәсыйхәт бирү. М.Гафуриның башлангыч чор иҗатында дидиктика - үгет-нәсыйхәт бирүнең өстенлек алуы. Үгет-нәсыйхәт бирүнең төп мотивы – кешене әхлаклы, аң-белемле итү. Лирик герой ихлас, гадел, ярдәмчел булырга, дөнья малына, аның ләззәтләренә кызыкмаска чакыра. М.Гафури иҗатында Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән традицияләрнең дәвам ителүе. Ритм, рифма, строфа үзенчәлекләре. Габдулла Тукайның «Дустларга бер сүз», «Мәхәббәт», «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырьләре. Тормыш юлын, иҗатын искә төшерү, өстәмә мәгълүмат бирү. Шагыйрь иҗатының чорларга бүленеше, һәр чорга хас сыйфатлар. Лирик төр, лирик жанр үзенчәлекләре. Лирик герой образы. Шагыйрь иҗатында күтәрелгән төп мотивлар: уку-гыйлем –татар халкының наданлыгы, артталыгы өчен борчылу, бу хәлдән чыгу юллары турында уйлану; мәхәббәт – эчкерсез саф мәхәббәткә, аның кодрәтенә, хатын-кыз гүзәллегенә дан җырлау; шагыйрь – шагыйрьлек эше милли азатлык өчен көрәш идеясе белән үрелү. Тел-сурәтләү чаралары. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.Гражданлык лирикасы | **3с.** |
| **XX гасыр башы әдәбиятында психологизм** | Шәриф Камалның «Буранда» хикәясе. Язучының тормыш юлын искә төшерү. «Буранда» хикәясендә авторның төп максаты – Мостафаның кичерешләрен аңлату. Ананың хәсрәтле тормышы, төп геройның үкенү сәбәпләре икесенә карата да кызгану хисләре уята. Буран образы – адаштыра торган табигать күренеше генә түгел, Мостафаның әнисенә булган мөнәсәбәтендә зур ялгышуы, адашуы, хәзерге хисләре, күңел халәте. Әсәрнең фаҗигале тәмамлануы, аеруча үкенеч белән тасвирлануы хикәяне онытылмаслык итеп истә калдыра. Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасы: кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту.Троплар. Әсәрнең пафосы – сентименталь пафос. Язучы стиле. Әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль. | **2с.** |
| **XX гасыр башы әдәбиятында сызлану фәлсәфәсе** | Фатих Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясе. Язучының тормыш юлын искә төшерү. Хикәядә авыр, кайгылы хәлләрнең сурәтләнүе. Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхетнең вакытлы булуы аша тормышның мәгънәсе юклыкка төшенү. Әсәрнең эчке катламын музыка аша бирү: Сөләйман карт елавы, капка, кыңгырау, бакча, сандугач тавышы, гитараның моңлы уйнавы, карчыкның йөткерүе карга каңгылдавы. Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасы: кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту.Троплар. Әсәрнең пафосы (сентименталь пафос), фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Язучы стиле: хикәя тормыш –яшәешкә ләгънәт укый, экзистенциализм фәлсәфәсен белдерә. | **4с.** |

| | | |
|---|---|---|
| **XX гасыр башы әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе** | Фәтхи Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе. Язучының тормыш юлы белән танышу. «Таһир-Зөһрә» трагедиясен уку. Драма төренә анализ ясау үзенчәлекләрен искә төшерү. Конфликтын билгеләү. Шигырь белән язылган, дастан сюжетына нигезләнгән булуы, дөнья әдәбиятында киң таралган мәхәббәт һәм мәкер, гаделлек һәм явызлык көрәше. Трагедиянең пафосын (трагик пафос), язучы стилен билгеләү – әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль. | **4 с.** |
| **20-30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе һәм яңа тормыш өчен көрәш романтикасы** | Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы. Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Фаҗигале драма жанрында язылган әсәрнең сюжет-композициясен ачыклау. Кеше бәхете темасының бирелеше, драманың проблема, идеясен билгеләү . Төп образларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешен өйрәнү. Портрет. Психологизм . Язучы стиле - фаҗигале.<br>30 нчы еллар әдәбиятында көрәш романтикасын сурәтләү. Тормышны матурлап, шартлылык кануннарына буйсындырып тасвирлау. Заманга хас яңа герой эзләү. Әдәби барыш: чор әдәбияты. Һади Такташның «Алсу» поэмасы. Үз чорының кичерешләрен, каршылыкларын чагылдырган иң популяр, танылган шагыйрь, прозаик, драматург буларак тормышы, иҗаты белән таныштыру. «Алсу» поэмасында яшьлекнең, көрәш романтикасының сурәтләнеше. Әдәби төр һәм жанрлар. Лиро-эпик жанр – поэма. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Характер. Лирик герой, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.<br>Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Психологизм.<br>Мәхәббәт, гаилә кору темасын ачу. Конфликтның кемнәр арасында баруы, сәбәпләре, чишелеше ягыннан әсәрне анализлау. Төп конфликтның эчке конфликт булуына басым ясау. Галиянең хатларны үзе өчен язуын ачыклау. Сюжет этапларыначу. Эпистоляр повесть жанры. | **10с.** |
| **Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты** | Фатих Кәримнең «Сибәли дә сибәли», «Ант», «Ватаным өчен», «Теләк», «Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Бездә яздыр», «Газиз әнкәй» шигырьләре. Тормыш юлы турында мәгълүмат. Иҗатының чорларга бүленеше. Сугыш чоры иҗатының үзенчәлекләре: җиңүгә ышаныч белән илен сакларга ант итү; лирик геройның рухи дөньясы баю; яшәү һәм үлү турында фәлсәфи уйлануы; фашизмга нәфрәт хисләре; туган ягын, якыннарын сагыну. Гражданлык лирикасы, күңел лирикасы.Сугыш чорында шагыйрь иҗатының поэма һәм баллада жанрында иң югары ноктага җитүе. «Кыңгыраулы яшел | **4 с.** |

| | | |
|---|---|---|
| | гармун» поэмасында сугышчының күңел дөньясы, хис-кичерешләрен лирик планда сурәтләү. «Сибәли дә сибәли» шигырендә сугыш фаҗигасен табигать күренешләре, тел-сурәтләү чарасы сынландыру, әдәби алым кабатлау аша тасвирлау. | |
| **60-80 нче еллар әдәбияты** | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы<br>Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте. (кыскартып). Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повестьта халык тормышының тулы бер панорамасы чагылу. Әсәрдә туган ил, халкың белән горурлану хисе тасвирлана, повесть укучыларда хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли. Сурәтләнгән геройларның, вакыйга-күренешләрнең тормышчан булуы, шулар аша әдип татар авылының үткәнен һәм бүгенгесен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, халыкның күңел байлыгын, гомумән, милли сыйфатларын тасвирлый. Г.Бәширов - портрет, табигатьбизәкләре, характер остасы; Гумәробразының бирелеше. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Язучы стиле.<br>Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестеЯзучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повесть жанры. Хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмияте. Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. Тел-стиль чаралары. Әсәр исеменең эчке һәм тышкы мәгънәгә ия булуы. Заманга тәнкыйди бәя. Язучы стиленең үзенчәлекләре.<br>Миргазиян Юныс “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повесте Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повесть жанры. Хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмияте. Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. Тел-стиль чаралары. Әсәр исеменең эчке һәм тышкы мәгънәгә ия булуы. Заманга тәнкыйди бәя. Язучы стиленең үзенчәлекләре. Сөйләм үстерү Әдәби әсәргә бәя<br>Равил Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга…», «Аккошлар», «Мин сиңа йомшак таң җиле…»“Вакыт”, “Якты моң”, һәм кыска шигырьләре.<br>Шагыйрьнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Иҗатка 60 нчыеллардакилүе, яңача ритмика, рифма, образларсистемасытудыруы. Р.Фәйзуллинкыскаформаларгамөрәҗәгатьитә, аларда метафора алгыплангачыга. Лирик әсәрләргә анализ ясауүзенчәлекләре. Табигыйхис-кичерешләрчагылыштапканшигырьләренең җырларбулыпкитүе. Фәлсәфи лирика. | **24 с.** |

| | | |
|---|---|---|
| | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе. Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Каршылыкның төрләре: төп сюжет сызыгында тышкы каршылык Әлмәндәр һәм Әҗәл арасында, эчке каршылык Әҗәл күңелендә; ярдәмче сюжет сызыкларында тышкы каршылык Әлмәндәр белән Өммия, Әлмәндәр белән Искәндәр арасында формалаша. Төп сюжет сызыгындагы эчке каршылыкның төп каршылык булуы. Әсәрнең фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Әлмәндәр образының бирелеше, аның замандаш сыйфатларын туплаган, халыкчан образ-характер булуы. Комедиянең тел-сурәтләү чараларына, кинаяле тезмәләргә байлыгы. Реаль тормыш картиналарының шартлылык һәм символлар белән тыгыз кушылып китүе, шуның белән әсәрдәге төп идеяне тулырак ачуга ирешү.<br>Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте. Әдипнең тормышы, иҗаты турында мәгълүмат бирү. «Җилкәннәрҗилдәсынала» повестеның–автобиографик повесть булуы. Кешенеданлау, зурлаутемасыныңбирелеше. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Язучы стиле.<br>Мөдәррис Әгъләмовның «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру. Классик шигырьгә йөз тотып иҗат итүе. Кешене данлау, зурлау темасының бирелеше. Лирик әсәрләргә анализ ясау үзенчәлекләре. Лирик жанрлар: гражданлык лирикасы, күңел лирикасы. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Шигырь төзелеше. Язучы стиле: экзистенциаль башлангыч. | |
| | Барысы | **58 с.** |

**КАЛЕНДАРЬ ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**

Дәреслек:8сыйныф .Әдәбият.Ганиева Ф,Ә. Рамазанова Ч.Р. 2015.ГУП “Татарское книжное издательство”

| № | **Өйрәнелә торган бүлек, дәрес темасы** ы | Сәг. саны | Календарь вакыт | | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План.вакыт | Фактик вакыт | |
| **Сәнгать төре буларак әдәбият** | | | | | |
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият | 1 | 9.09 | | Сорауларга тулы һәм төгәл җаваплар бирергә күнегү. Әңгәмә кора белү. |
| **Урта гасырлар әдәбияты. Казан ханлыгы чоры.** | | | | | |
| 2 | Казан ханлыгы чорына кыскача тарихи, мәдәни, әдәби күзәтү. Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында мәгълүмат. | 1 | 10.09 | | Казан ханлыгы чорына кыскача тарихи, мәдәни, әдәби күзәтү ясау. |
| 3 | Мөхәммәдьярның «Нәсыйхәт» шигыре. | 1 | 16.09 | | Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар һәм үгет–нәсыйхәтчелекне аңлату. |
| **XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек әдәбияты** | | | | | |
| 4 | Чорга кыскача тарихи күзәтү. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. | 1 | 17.09 | | Чорга кыскача тарихи күзәтү ясау. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәтен аңлату. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5-6 | Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» повесте. | 2 | 23.09<br>24.09 | | Мәгърифәтчелек әдәбиятында төп тема - аң-белем, әхлак, тәрбия, һөнәрле булу, төп каршылык – искелек һәм яңалык көрәше булуын ачыклау. |
| 7 | БСҮ. Төп образларгша характеристика язу. | 1 | 26.09 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, Хисаметдин менла һәм Хәнифә язмышына үз мөнәсәбәтләре турында язма сөйләм оештыру. |
| **XX гасыр башы әдәбиятының үзенчәлеге.** | | | | | |
| 8 | XX гасыр башы әдәбиятының үзенчәлеге. | 1 | 28.09 | | XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүен ачыклау. |
| **XX гасыр башы әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр** | | | | | |
| 9 | М.Гафуриның тормышы һәм иҗаты. «Нәсыйхәт» шигыре. | 1 | 3.10 | | М.Гафуриның башлангыч чор иҗатында дидиктика - үгет-нәсыйхәт бирүнең өстенлек алуын аңлату. М.Гафури иҗатында Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән традицияләрнең дәвам ителүен ачыклау. |
| 10 | Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты. Г.Тукайның «Дустларга бер сүз», «Мәхәббәт», «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырьләре. | 1 | 5.10 | | Шагыйрь иҗатында күтәрелгән төп мотивлар: уку-гыйлем –татар халкының наданлыгы, артталыгы өчен борчылу, бу хәлдән чыгу юллары турында уйлану; мәхәббәт – эчкерсез саф мәхәббәткә, аның кодрәтенә, хатын-кыз гүзәллегенә дан җырлау икәнлеген ачыклау. |
| 11 | Г.Тукай иҗатында дин фәлсәфәсе. | 1 | 10.10 | | Шагыйрь иҗатында күтәрелгән дин фәлсәфәсен өйрәнү. |
| 12 | **БСҮ.** Г.Тукай иҗаты буенча инша язарга әзерләнү. | 1 | 12.10 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, Г.Тукай турында язма сөйләм оештыру. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **XX гасыр башы әдәбиятында психологизм** | | | | | |
| 13 | Күңел газаплары аша рухи үсешкә. | 1 | 17.10 | | «Буранда» хикәясендә авторның төп максаты – Мостафаның кичерешләрен аңлату икәнлеген ачыклау. |
| 14 | Ялгышлар гомерлек күңел газабына сала | 1 | 19.10 | | Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасын ачыклау. |
| **XX гасыр башы әдәбиятында сызлану фәлсәфәсе** | | | | | |
| 15 | Матурлык, бәхет, мәхәббәт, яшьлек – барысы да вакытлыча гына | 1 | 24.10 | | Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхетнең вакытлы булуы аша тормышның мәгънәсе юклыкка төшенү. |
| 16 | “Бер хәрабәдә...” хикәясенең сәнгатьчә эшләнеше. | 1 | 26.10 | | Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасын ачыклау. Төп образларга бәя бирү. |
| 17 | **БСҮ.** “Бер хәрабәдә...” хикәясенә бәяләмә язу. | 1 | 7.11 | | “Бер хәрабәдә...” хикәясенә бәяләмә язу. |
| 18 | К.Тинчуринның тормышы һәм иҗаты. “Искәндәр” хикәясе. | 1 | 9.11 | | 30 нчы еллар әдәбиятында көрәш романтикасын сурәтләү икәнлеген ачыклау. |
| 19 | К.Тинчуринның “Хәкимҗан агай” хикәясе. | 1 | 14.11 | | Тормышны матурлап, шартлылык кануннарына буйсындырып тасвирлау үзенчәлекләрен ачу. |
| **XX гасыр башы әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе** | | | | | |
| 20 | Фәтхи Борнашның тормышы һәм иҗаты. «Таһир-Зөһрә» трагедиясе. | 1 | 16.11 | | Драма төренә анализ ясау үзенчәлекләрен искә төшерү. Конфликтын билгеләү. |
| 21 | Фәтхи Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясендә сурәтләнгән вакыйгалар. | 1 | 21.11 | | Шигырь белән язылган трагедиянең дастан сюжетына нигезләнгән булуын дәлилләү. |
| 22 | Фәтхи Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясендә мәхәббәт һәм мәкер, гаделлек һәм явызлык көрәше проблемалары. | 1 | 23.11 | | Дөнья әдәбиятында киң таралган мәхәббәт һәм мәкер, гаделлек һәм явызлык көрәшенең бирелешен ачыклау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 23 | Фәтхи Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясендә конфликт. | 1 | 28.11 | | Трагедиянең пафосын (трагик пафос), язучы стилен билгеләү |
| **20-30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе һәм яңа тормыш өчен көрәш романтикасы** | | | | | |
| 24 | К.Тинчурин – драматург. | 1 | 30.11 | | Язучы иҗаты буенча хронология булдыру. |
| 25 | К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә эчке һәм тышкы конфликтлар. | 1 | 5.12 | | Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләрен кабатлау. Фаҗигале драма жанрында язылган әсәрнең сюжет-композициясен ачыклау. |
| 26 | К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә бәхет темасы. | 1 | 7.12 | | Кеше бәхете темасының бирелеше, драманың проблема, идеясен билгеләү. |
| 27 | К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәренең сәнгатьчә эшләнеше. | 1 | 12.12 | | Төп образларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешен өйрәнү. |
| 28 | **БСҮ**. К.Тинчурин иҗаты буенча сочинение язарга әзерләнү. | 1 | 14.12 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, К.Тинчурин иҗаты буенча язма сөйләм оештыру. |
| 29 | Һ.Такташның тормышы һәм иҗаты. “Алсу” поэмасы. | 1 | 19.12 | | Үз чорының кичерешләрен, каршылыкларын чагылдырган иң популяр, танылган шагыйрь, прозаик, драматург буларак тормышы, иҗаты белән танышу. |
| 30 | Һ.Такташның “Алсу” поэмасында яңа тормыш төзү романтикасы. | 1 | 21.12 | | «Алсу» поэмасында яшьлекнең, көрәш романтикасының сурәтләнешен күзәтү. |
| 31 | Гадел Кутуйның тормышы һәм иҗаты. «Тапшырылмаган хатлар» повесте. | 1 | 9.01 | | Язучы иҗаты буенча хронология булдыру. |
| 32 | Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда конфликт | 1 | 11.01 | | Мәхәббәт, гаилә кору темасын ачу. Конфликтның кемнәр арасында баруы, сәбәпләре, чишелеше ягыннан әсәрне анализлау. |
| 33 | Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенең сюжет-композиция үзенчәлекләре. | 1 | 16.01 | | Төп конфликтның эчке конфликт булуына басым ясау. |
| 34 | Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенең стиль үзенчәлекләре. | 1 | 18.01 | | Галиянең хатларны үзе өчен язуын ачыклау. Сюжет этапларын ачу. |
| 35 | **БСҮ**. Г.Кутуй иҗаты буенча сочинение язарга әзерләнү. | 1 | 23.01 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, Г.Кутуй иҗаты буенча язма сөйләм оештыру. |
| **Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 36 | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты | 1 | 25.01 | | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты үзенчәлекләре белән танышу. |
| 37 | Фатих Кәримнең тормышы һәм иҗаты. «Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Ант», «Ватаным өчен» шигырьләре. | 1 | 30.01 | | Ф.Кәрим иҗаты буенча хронология төзү |
| 38 | Фатих Кәримнең«Сибәли дә сибәли»,«Теләк», «Бездә яздыр» шигырьләре. | 1 | 1.02 | | Сугыш чорында шагыйрь иҗатының поэма һәм баллада жанрында иң югары ноктага җитүен ачыклау. |
| 39 | Фатих Кәримнең «Газиз әнкәй» шигыре, «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасы. | 1 | 6.02 | | Ф.Кәрим шигырьләрендә сугыш фаҗигасен табигать күренешләре, тел-сурәтләү чарасы сынландыру, әдәби алым кабатлау аша тасвирлау икәнлеген аңлату. |
| **60-80 нче еллар әдәбияты** | | | | | |
| 40 | Гомәр Бәшировның тормышы һәм иҗаты. «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте. | 1 | 9.02 | | Г.Бәширов иҗаты буенча хронология төзү. |
| 41 | Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестенда халык тормышының бирелеше. | | 15.02 | | Повестьта халык тормышының тулы бер панорамасы чагылганлыгын билгеләп күрсәтү. |
| 42 | Г.Бәширов - портрет, табигатьбизәкләре, характер остасы | 1 | 16.02 | | Сурәтләнгән геройларның, вакыйга-күренешләрнең тормышчан булуы, шулар аша әдип татар авылының үткәнен һәм бүгенгесен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, халыкның күңел байлыгын, гомумән, милли сыйфатларын тасвирлавын аңлату. |
| 43 | Г.Бәширов иҗаты һәм «Туган ягым – яшел бишек» повестеның татар әдәбиятында тоткан урыны. | | 22.02 | | Әсәрне анализлау аша анда туган ил, халкың белән горурлану хисе тасвирлануын, повесть укучыларда хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли икәнен ачыклау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 44 | **БСҮ.** “Татар әдәбиятында туган як темасы” дигән темага сочинение язарга әзерләнү. | 1 | 1.0<br>2 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, татар әдәбиятында туган як темасының бирелеше турында язма сөйләм оештыру. |
| 45 | Аяз Гыйләҗевнең тормышы һәм иҗаты. | 1 | 2.0<br>2 | | Аяз Гыйләҗев иҗаты буенча хронология төзү. |
| 46 | Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. | 1 | 9.0<br>3 | | Әсәрдәге хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнарын ачыклау. |
| 47 | Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә төп образлар. | 1 | 15.<br>03 | | Төп образларга бәя бирү. |
| 48 | Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә кулланылган тел-стиль чаралары. | 1 | 16.<br>03 | | Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә кулланылган тел-стиль чараларын ачыклау. |
| 49 | М.Юнысның тормышы һәм иҗаты. “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повесте | 1 | 22.<br>03 | | Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмиятен билгеләү. |
| 50 | М.Юнысның “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повесте хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. | 1 | 02.<br>04 | | Әсәрдәге хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнарын ачыклау. |
| 51 | М.Юнысның “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повестенда төп образлар. | 1 | 05.<br>04 | | Төп образларга бәя бирү. |
| 52 | М.Юнысның “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повестенда эчтәлек һәм форма, сәнгать алымнары. | 1 | 9.0<br>4 | | Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. |
| 53 | Равил Фәйзуллинның тормышы һәм иҗаты. «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга…», “Вакыт” шигырьләре. | 1 | 13.<br>04 | | Равил Фәйзуллин иҗаты буенча хронология төзү. Лирик әсәрләргә анализ ясау үзенчәлекләрен кабатлау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 54 | Равил Фәйзуллинның «Аккошлар», «Мин сиңа йомшак таң җиле…» “Якты моң” һәм кыска шигырьләре. | 1 | 15.<br>04 | | Равил Фәйзуллинның яңача ритмика, рифма, образларсистемасытудыруын ачыклау. |
| 55 | **БСҮ**. Равил Фәйзуллин иҗаты буенча сочинение язарга әзерләнү. | 1 | 19.<br>04 | | Җөмләләрне эзлекле рәвештә бәйләнешкә кертеп, Р.Фәйзуллин иҗаты буенча язма сөйләм оештыру. |
| 56 | Туфан Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. «Әлдермтөп образлар.ештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе. | 1 | 22.<br>04 | | Туфан Миңнуллин иҗаты буенча хронология төзү. |
| 57 | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә эчке һәм тышкы конфликтлар. | 1 | 17.<br>04 | | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә эчке һәм тышкы конфликтларны табу. |
| 58 | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә төп образлар. | 1 | 19.<br>04 | | Әлмәндәр образының бирелешен, аның замандаш сыйфатларын туплаган, халыкчан образ-характер булуын аңлату. |
| 59 | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә шартлылык һәм символлар. | 1 | 24.<br>04 | | Реаль тормыш картиналарының шартлылык һәм символлар белән тыгыз кушылып китүен, шуның белән авторның әсәрдәге төп идеяне тулырак ачуга ирешүен күзәтү. |
| 60 | Фәнис Яруллинның тормышы һәм иҗаты. «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте. | 1 | 26.<br>04 | | Фәнис Яруллин иҗаты буенча хронология төзү. |
| 61 | Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кешене данлау, зурлау темасының бирелеше. | 1 | 1.0<br>5 | | «Җилкәннәрҗилдәсынала» повестеныңавтобиографик повесть булуын дәлилләп аңлату. |
| 62 | Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда тема, проблема, идея, пафос. | 1 | 3.0<br>5 | | Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кешене данлау, зурлау темасының бирелешен ачыклау. |
| 63 | **БСҮ.** Бәяләмә язарга әзерләнү. | 1 | 8.0<br>5 | | Әсәр буенча бәяләмә язарга әзерләнү. Бәяләмә язу үзенчәлекләрен искә төшерү. |
| 64 | Мөдәррис Әгъләмовның тормышы һәм иҗаты. «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре. | 1 | 10.<br>05 | | Мөдәррис Әгъләмов иҗаты буенча хронология төзү. |
| 65 | Мөдәррис Әгъләмовның “Җил дә җил”, “Без”, “Сабантуй” шигырьләре. | 1 | 15.<br>05 | | Шигырьләрдә кешене данлау, зурлау темасының бирелешен күзәтү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 66 | **Арадаш аттестация**Татар әдәбиятында шагыйрәләр иҗаты: Л.Шагыйрьҗан, Э.Мөэминова, Н.Сафина, Р.Вәлиева, Б.Рәхимова, Э.Шәрифуллина, А.Минһаҗева. Шагыйрәләр иҗатын өйрәнеп, проектлар яклау дәресе. | 1 | **17. 05** | | Сүзлек өстендә эш. Әсәрләрне актер укуында тыңлау. Өлешләргә бүлү. сорауларга җавап. Лирик геройның кичерешләрен аңлату. Язучыларның мәхәббәт турындагы фикерләрен уку. |
| 67 | **Сыйныфтан тыш уку.** Мәдинә Мәликова “Чәчкә балы” | 1 | 22. 05 | | Әсәрне уку, сорауларга җавап бирү, укылган буенча фикер алышу. |
| 68 | **Сыйныфтан тыш уку.** Фәүзия Бәйрәмова “Кыңгырау” | 1 | 24. 05 | | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, мөһим вакыйгаларны аерып ала белергә күнектерү. Бәйләнешле сөйләм төзү. |
| 69 | **Сыйныфтан тыш уку.** Хәзерге татар әдәбиятында яшьләр иҗаты. Проектлар яклау дәресе. | 1 | 29. 05 | | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, мөһим вакыйгаларны аерып ала белергә күнектерү. Бәйләнешле сөйләм төзү. |
| 70 | **Йомгаклау дәресе.** | 1 | 31. 05 | | Ел буена үткәннәргә йомгак ясау. |